МИНИСТЕРСТВ ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МОНОСЭБОТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ | БОЕРЫК

07.07.2023 Казан ш. № 1859-р

Бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Актаныш, Буа, Биектау, Чүпрәле, Зәй, Кайбыч, Кама Тамагы, Мөслим, Питрәч, Сарман, Тәтеш муниципаль районнары территорияләрендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) чикләрен раслау турында” 30.12.2013 № 4083-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында” 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ башкарган документациягә туры китереп, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе хатын исәпкә алып (04А-04/1429 от 13.06.2023) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан

Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милке булган, Кайбыч муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Актаныш, Буа, Биектау, Чүпрәле, Зәй, Кайбыч, Кама Тамагы, Мөслим, Питрәч, Сарман, Тәтеш муниципаль районнары территорияләрендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) чикләрен раслау турында” 30.12.2013 № 4083-р Карары (алга таба - № 4083-р Карар) белән урнаштырылган 27674 инвентарь номерлы бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасын 16:21:140604:13, 16:21:000000:1098 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә күрсәтелгән газүткәргечнең 105,4 м.ына демонтаж ясалу һәм 143 м. монтаж ясау сәбәпле «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ башкарган территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, үзгәртергә. Бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасы озынлыгы гомуми мәйданы (36261 ± 67) кв.м.лы территория рәвешендә 2463 м.ны тәшкил итә.

2. Инвентарь номеры 27674 булган бүлгеч газүткәргечне эксплуатацияләү срогында әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ башкарган территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлеге нигезендә № 4083-р Карарга (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 28.12.2018 № 4633-р, 05.11.2020 № 3401-р, 07.04.2021 № 1121-р, 24.03.2023 № 779-р, 29.03.2023 № 844-р, 24.05.2023 № 1365-р Карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Кайбыч районы территориясендә әлеге карарның 6 нчы кушымтасындагы инвентарь номерлы, 306,808 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 1,5096 кв.км территорияне тәшкил иткән газ бүлү газүткәргечен

«Граница» кадастр үзәге» ҖЧҖ, «РКЦ «Земля» АҖ, «Кадастр недвижимости» ҖЧҖ, «Гео-Инженеринг» ҖЧҖ, “БАРС” ҖЧҖ, «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ тарафыннан башкарылган җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зонасы картасында (планда) булган белешмәләр нигезендә;

әлеге карарның 6 нчы кушымтасындагы 27674 инвентарь номерлы газ бүлү газүткәргеченә туры килгән юлны әлеге карарның кушымтасы редакциясендә бәян итәргә (бастырып чыгару каралмаган).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**